ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31.01.2025 Баулы шәһәре №21

Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннары реестрын һәм схемасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 маддәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару Кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 1039 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кушымталарны расларга:

- Татарстан Республикасы "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннары реестры (1 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннары схемасы (2 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау урынын (мәйданчыгын) булдыруны килештерү турында гариза формасы (3 нче кушымта);

- каты коммуналь калдыклар туплану урыны (мәйданчыгы) турында белешмәләрне Татарстан Республикасы "Баулы шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплану урыннары (мәйданчыклары) реестрына кертү хакында гариза формасын (4 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы (http://www.bavly.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю. Соколов